ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

31.01.2023　　　　　　с. Печищи　　　　　　№ 1

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегендә 2023нче елда җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук Печищиавыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Печищи авыл җирлеге башлыгы　　　　Е.В. Рахматулина

Печищи авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023нче елның 31 гыйнварыннан 1 номерлы карарына

1 нче кушымта

.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегендә 2023нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4029,78 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1249,40 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2514,30 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Печищи авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023нче елның 31 гыйнварыннан 1 номерлы карарына

2нче кушымта

.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегендә 2023нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Тәнне төрү | 745,61 |
| 3. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3284,17 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1249,40 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2514,30 |
| Барлыгы | 7793,48 |